# ДЖЕЙМС ГАЙ – ИРЕКЛЕ СТИЛЬ БЕЛӘН 200 МЕТР ДИСТАНЦИЯГӘ ЙӨЗҮ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ

04.08.2015, 17:40
СПОРТ

**Әлеге минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында финал ярышы тәмамланды. Ирекле стиль белән 200 метр дистанциягә йөзүдә дөньяның иң әйбәт 8 йөзүчесе катнашты.**

Беренче алтын медальне британияле Джеймс Гай алды. Ул дистанцияне иң әйбәт күрсәткеч белән үтте – 1:45.14. Аның артыннан финишка Кытай йөзүчесе Сунь Ян килде. Аның күрсәткече – 1:45.20. Призлы өчлекне немец Пол Бьердманн япты – ул дистанцияне 1:45.38 күрсәткече белән үтте.

Билгеләп үтәбез, ирекле стиль белән 400 метр дистанциягә йөзү буенча көмеш алып, алдарак ДЧ-2015тә Гай инде пьедесталга менгән иде. Ә Сунь Ян агымдагы су мундиалендә әлеге спорт төре буенча беренче җиңүче булды.

ДЧ-2015. Йөзү.

Ир-атлар. Ирекле стиль. 200 м.

1. Джеймс Гай (Бөекбритания) – 1:45.14

2. Сунь Ян (Кытай) – 1:45.20

3. Пол Бьердманн (Германия) – 1:45.38

4 август. Казан. “Казан Арена”.

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА